ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.12.2020 Казан шәһәре № 732/2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүленешле электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 29 июнендәге 164 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 163 номерлы, 2018 елның 25 октябрендәге 305 номерлы, 2019 елның 22 ноябрендәге 392 номерлы, 2020 елның 10 июлендәге 257/2020 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан территориаль бүленешле электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора: территориаль | Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | бүленешле электр челтәрләренә технологик ялгануга түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын билгеләгәндә челтәр оешмасы гамәлләренең дөреслеге;<br>мөрәҗәгать итүче үз таләпләрен нигезли торган шартлар территориаль бүленешле электр челтәрләренә технологик ялгануга түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын куллануга бәйле бәхәс предметы булып тормаса.<br>Дәүләт хезмәте туктатып торылырга мөмкин, түбәндәгеләр таләп ителгәндә:<br>җайга салу органы тарафыннан өстәмә белешмәләр алу яисә бәхәсне карауга башка затларны җәлеп итү;<br>экспертиза үткәрү | Кагыйдәләрнең 13 пункты |

";

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>мәгълүмати стенд белән.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә аша, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, Мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның да чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, мәгълүмат такталарында урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, объектлардан һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:<br>объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары; | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;<br>объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга объектларда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;<br>хезмәттән файдалану өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада хезмәт күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, хезмәттән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;<br>инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү | |

";

3.5.10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.10. Рәис (рәис урынбасары) киңәшмә уздыра, аның нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яки өлешчә) канәгатьләндерү турында рәиснең (рәис урынбасарының) тиешле боерыгы проектын әзерләү зарурилыгы турында;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында рәиснең (рәис урынбасарының) тиешле боерык проектын әзерләү зарурилыгы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура киңәшмә узган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәиснең (рәис урынбасарының) таләпләрне канәгатьләндерү яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карары, киңәшмәнең рәсмиләштерелгән беркетмәсе.».

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В.Хабибуллина